| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ** | | **БОЕРЫК** |
| 27.12.2017 | г. Казань | № 3076-р |

**Биналарны (каралтыларны, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү турында**

“Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясын, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 1.1 статьясын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге № 977 карары белән расланган Салым салу максатларында биналарны (каралтыларны, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү тәртибен һәм Салым салу максатларында биналарны (каралтыларны, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссия турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 22 август, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.101 пунктына, һәм Салым салу максатларында биналарны (каралтыларны, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссиясенең 2017 елның 22 декабрендәге № 6 карарына нигезләнеп:

1. Әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән объектларга карата биналарның (каралтылар, корылмалар) һәм бүлмәләрнең – сәүдә үзәкләренең (комплекслар) фактта файдалану төрен билгеләргә.
2. Карарны www.mzio.tatarstan.ru. адресы буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында бастырып чыгарырга:
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән башлап үз көченә керә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы Җир
һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының 27.12.2017
№ 3076-р карарына кушымта

| № п/п | Кадастр номеры | Адрес | Мәйдан, кв.м. |
|---|---|---|---|
| 1 | 16:50:050152:3108 | Татарстан Республикасы, Казан ш., Җиңү проспекты, 157 й. | 2 605,6 |
| 2 | 16:50:110405:1040 | Татарстан Республикасы, Казан ш., Ямашев пр-кты, 38 й. | 2 954,5 |
| 3 | 16:50:171201:1002 | Татарстан Республикасы, Казан ш., Идел буе р-ны, Оренбург тракты ур., 160 й., корп.2 | 20 870,3 |
| 4 | 16:52:020301:1750 | Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Магистраль ур., 16 й. | 4 236,1 |
| 5 | 16:52:060204:5725 | Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Сөембикә пр-кты, 74А й. | 2 465,2 |
| 6 | 16:52:070101:283 | Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Вахитов пр-кты, 9А й. | 2 043,6 |
| 7 | 16:45:010115:155 | Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт ш., Ленин ур., 60 й. | 3 572,5 |